Миңзәлә шәһәре гимназиясе
Киләчәкнең башы - бүгенгедә
1998

**2019 ел, НОЯБРЬ**

**киләчәкне яктырта**

# Яшьлек







# Җәннәт әниләрнең аяк астында!

**Әни - кеше тормышындагы иң мөһим һәм кадерле кеше. Әниләргә багышлап, күпме шигырьләр язылган да, күпме җырлар җырланган... Тик гел яңалары туа тора, чөнки әни кешегә күпме генә матур, җылы сүзләр әйтсәң дә аз булачак һәм хисләрне аңлатырга җитмәячәк…**






Сезнең иңнәргә бик зур йөк - гаилә мәшәкатьләре дә, һөнәри эшчәнлек тә, балалар тәрбияләү дә төшә.
Барысы өчен дә бик зур рәхмәт!
Кадерледән кадерлеләребез!
Сезгә озын гомер, имин көннәр, балаларыгызның куанычларын гына күреп яшәвегезне телим.
Күңелегез тыныч, килер көннәрегез матур һәм һәрчак бәхетле булыгыз!



29 ноябрь көнне мәктәптә Халыкара Әниләр көненә багышланган бәйрәм узды. Мәктәп залы кунаклар белән тулы иде, алар арасында әниләр, әбиләр, укучылар, укытучылар да бар иде. 7 сыйныф алып баручылары барлык кунакларны сәламләделәр һәм бәйрәм белән котладылар. Кунаклар, балаларның чыгышларын карап, рәхәтләнеп шатландылар. Бәйрәм дәвамында Әниләр көненә багышланган төрле презентацияләр, видеороликлар күрсәтелде. Мәктәп коридорларында бәйрәм газеталары эленгән иде. Кон-

# Өстәмә түгәрәкләр!

Өстәмә түгәрәкләр!

Безнең мәктәптә "Тылсым" театр түгәрәге үз эшен башлап җибәрде! Тукай абыебыз, юкка гына “Театр яктылыкка, нурга илтә, кирегә илтми, уңга илтә” дип әйтмәгән. Чыннан да, театр дөньясы бөтенләй башка атмосферага ия. Шуңа күрә укучылар шушы түгәрәккә бик яратып йөриләр! Афәрин!

**Г.С.Хәлиуллина, гимназия директоры**



1906 елның 22 декабре тарихка татар театрының туган көне булып кереп калган. Бу көнне Казанның Горький урамындагы 3 -нче йортында урнашкан Яңа клубта киң катлау тамашачылар өчен ярлы студентлар файдасына беренче мәртәбә татарча ачык спектакль күрсәтелә. Бу кичтә сәхнәдә «Кызганыч бала» драмасы һәм «Гыйшык бәла-



се» ко-медиясе уйнала.

Профессиональ татар театры труппасын оештыручы булып Оренбург шәһәреннән укытучы, күпкырлы талант иясе Ильяс Кудашев-Ашказарский санала. А.Островский әсәре буенча үзе тәрҗемә иткән “Наданлык илә галимлек” пьесасын сәхнәләштереп, бу труппа Россия буйлап беренче гастрольгә чыга. Шунда бу иҗат төркеменә үзе исән вакытта ук “татар театрының атасы” дип аталган Габдулла Кариев килә һәм соңрак аның җитәкчесенә әйләнә. “Сәйяр”, ягъни “күчеп йөрүче йолдыз” исемен алган татар театры, үзенең беренче адымыннан башлап, халыкны мәгърифәткә, яктылыкка өндәүче, сәнгать учагы була. 1926 елда театрга “Академия”, ә 1939 елда Галиәсгар Камал исеме бирелә.

# Егетләр турында 3 миф
Егетләр турында 3 миф



**МИФ 1**
**ЧЫН ИР-ЕГЕТ, НИНДИ ЯШЬТӘ БУЛУЫНА КАРАМАСТАН, СПОРТ ЯРАТА**

Егет кешегә бокс та, биатлон белән футбол да бер үк дәрәҗәдә кызыклы. Ул үзе дә туп тибеп кайтырга яисә гер күтәреп алырга каршы түгел.


Дөреслек: социологлар исәбе буенча, егетләрнең 50% ы гына спорт белән кызыксына. Шуларның 10% ы гына ракетка белән теннис тубына эләгә ала. Ә ат янына 1000 нән берсе генә килергә җөрьәт итә икән.

**МИФ 2**
**ЕГЕТЛӘР БАЛЛЫ ЯРАТМЫЙ**

Алар кайнатмага да борыч салалар, ди, имеш.
ДӨРЕСЛЕК: ирләр организмында матдәләр алмашы хатын-кызларныкына караганда тизрәк бара. Шуңа күрә курсташларың, глюкоза кермәсә, имтихан уртасында “сүнәргә” мөмкин: фикерләү туктаячак, һәм шоколад кисәгеннән башка баш мие эшләп китә алмаска да мөмкин. Мармелад, әлбәттә, аларга шашлыкны алыштырмас, тик менә шоколадлы тортны егетләр бер утыруда ашап бетерә ала.

**МИФ 3**
**ЕГЕТЛӘР - ТУМЫШТАН ТӨЗҮЧЕЛӘР, САНТЕХНИКЛАР, СТОЛЯРЛАР**

Чын ир-ат эше – кадак кагу, краннары ремонтлау һәм урындык тәпиләрен кисү. Бу сәләт аларның канында.
ДӨРЕСЛЕК: урындыкның тәпиен ул, мөгаен, кисәр, ләкин сиңа аяксыз урындык нәрсәгә? Ә калганы, әлбәттә - үзләрен хатын-кызлар башкара торган йорт эшләреннән азат итү максатыннан иҗат ителгән легенда. Берни дә әйтеп булмый – бик хәйләкәр уйлап табылган! Бөтен кеше йомырка кыздыра һәм лампочка борып куя белергә тиеш. Монда җенесләргә аеру була алмый!




*Мәгълүмат «Ялкын» журналыннан алынды*

# Укучылар иҗаты!

***

Көннәр якты булсалар да ,
Төннәр караңгы, боек,
Шуңа да минем исемем -
Аталадыр төнбоек.

*Айзилә Хаматова*



## ТӨНБОЕК

Күл буенда, буада
Утыра бер ак чәчәк.
Яфраклары бик тә матур,
Исеме генә бик боек.
Боегып кына утыра ул,
Тирә-юньгә нур чәчә,
Юлчыларга сәлам юллый,
Изге теләкләр әйтә.
Күл буена төштем дә
Сорадым ак чәчәктән:
"Үзең шундый сылусың,
Син әллә су сылуы?"
Кинәт кенә болыт чыкты,
Матур чәчкәм йомылды.
Боегып калды тирә-ягым,
Исеме  булды"Төнбоек!"
Төнбоегым, борчылма син,
Тагы кояшлар чыгар.
Тирә-юньне балкытып тор,
Булма беркайчан боек.

*Илүзә  Гайниева*

* * *

Бала-чагым  әкиятләре -
“Су анасы”, “Шүрәле”.
Тукай абзыйга шуңа да
Мин бик-бик тә рәхмәтле.
Укыган саен укыйсы
Килә һәрбер язганын.
Тукайдан, туган телемнән
Аермасын язмышым!

*Язилә Мусина*



# Туган көннәр



**Укытучылар:**
Биктаһирова Роза  Александровна (01.11)
Камалова Лариса Рафаеловна (11.11)
1 нче А сыйныфы:
Рәхмәтуллина Рамилә (13.11)
Фәттахова  Сафина (10.11)
1 нче  Б сыйныфы:
Николаева  Аделина (29.11)
Шәйгарданова  Адилә (07.11)
2 нче сыйныф:
Батталов   Самат  (25.11)
3 нче сыйныф:
Салимгәрәева  Әмирә (22.11)
Фәррахов  Илназ (02.11)
Логинова  Карина (14.11)
4 нче сыйныф:
Гарипова Диләрә (12.11)
Закиров Илдан (08. 11)
Нуриева Ләйсирә (13.11)
Зарипова Самира (06. 11)
5 нче сыйныф:
Мөхәммәтова Алинә (05.11)
6 нчы сыйныф:
Кәлимуллин Фәрхәд (01.11)
Нуруллина Гузәл (02.11)
Хәмидов Ислам (14.11)
7 нче сыйныф:
Әхмәтшин Адель (28.11)
Сабитова Руфина (15.11)
Шалянин Адель
8 нче сыйныф:
Гафиятуллина Индира (28.11)
Логинова Аделина (19.11)
Нуриев Ислам (26.11.)









**Баш мөхәррир** —Крашева Рузалина
**Әдәби консультант-**Гарипова Рузиля, Мусина Язилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Маликова Камилә, Авзалтдинова Камилә, Мулләхмәтова Айзилә
**Фотокорреспондент-**Яковлева Алсу
**Проект житәкчеләре** —   татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт  кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745